ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 5 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:
а) 5 пунктта:
«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«в) һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында укучыларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге бүлектә укучы аспирантларга һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның докторантларына, дини белем бирү оешмаларында укучыларга түләнә торган стипендияләр, шулай ук күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнарга медицина күрсәткечләре буенча академик ялда булу чорындагы компенсация түләүләре;»;
«г» пунктчасында «һөнәри әзерлек, яңадан әзерлек һәм квалификация күтәрү» сүзләрен «һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу» сүзләренә алмаштырырга;
«и» пунктчасында «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 7 пунктта:
«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясенең таможня органнары һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә хокук саклау эшчәнлегенә бәйле федераль дәүләт хезмәте узу каралган башка органнар хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән даими башкарыла торган өстәмә түләүләр һәм азык-төлек белән тәэмин ителү;»;

«б» пунктчасында «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының» сүзләрен төшереп калдырырга, «хокук саклау хезмәтенең бүтән органнарыннан» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары нигезендә хокук саклау эшчәнлегенә бәйле федераль дәүләт хезмәте узу каралган башка органнардан» сүзләренә алмаштырырга;

«л» пунктчасында «акчалата түләүләр» сүзләреннән соң «(компенсацияләр)» сүзен өстәргә;

«н» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 8 статьяның 10 өлешендә «уңышлардан, продукциядән һәм керемнәрдән файдалану» сүзләрен «уңышны, продукцияне һәм керемнәрне бүлү турында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 статьяда:

а) 1 өлештә «исәпләп чыгарыла» сүзләрен «билгеләнә» сүзенә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «исәпләп чыгарыла» сүзләрен «билгеләнә» сүзенә алмаштырырга;

в) 3 өлештә «исәпләп чыгарыла» сүзләрен «билгеләнә» сүзенә алмаштырырга;

4) 14 статьяның 1 өлешендә «күчемсез мөлкәтне кадастр исәбенә куюны һәм дәүләт кадастрын алып баруны башкара торган органнан» сүзләрен «дәүләт кадастр исәбенә куюны, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрын алып баруны һәм Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында булган белешмәләрне бирүне гамәлгә ашыручы органнан (алга таба – хокукларны теркәү органы)» сүзләренә алмаштырырга;

5) 16 статьяның 2 өлешендә:

а) 1 пунктта «мөлкәткә хокукларны дәүләт исәбенә алу һәм теркәү органнарыннан һәм тиешле органнардан» сүзләрен «хокукларны теркәү органыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) әлеге Законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 4 – 6 пунктларында күрсәтелгән документларны.»;

6) 17 статьяда:

а) 1 өлештә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) торак бинада яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарның санын раслый торган белешмәләр;»;

6 пунктта «дәүләт теркәве органнарыннан белешмә» сүзләрен «хокукларны теркәү органыннан белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлештә «дәүләт хакимияте органнарына, салым һәм таможня органнарына, башка» сүзләрен «дәүләт органнарына, башка җирле үзидарә органнарына һәм» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 21 июнь
№ 48-ТРЗ